1. Морфема нәрсә ул? а) сүзнең мәгънәгә ия булган иң кечкенә берәмлеге; ә) сүзнең лексик мәгънәгә ия булган иң кечкенә берәмлеге; б) сүзнең грамматик мәгънәгә ия иң кечкенә берәмлеге; в) морфема ул - тамыр. 2. Морфемаларга дөрес бүленгән рәтне күрсәтегез: а) кай-та-лар, сү-зем-не; ә) кит-ә-сез, эш-лә-гән-сез; б) китап-лар-ы-быз-ны, эш-ләр-сез; в) китаб-ын, бала-лар-ыбыз. 3. Бер генә мәгънәле кисәктән торган сүзләр тезмәсе: а) элгеч, ңиләк; ә) сандугач, сыерчык,карлыган; б) сүзчән, кайтыр, уйламаган; в) бүген, керпе, алмагач. 4. Ясалма сүзләр рәтен күрсәтегез: а) йөрәк, сукмак, тояк; ә) кием, яшьрәк, алтынчы; б) кием, энием, керем; в) тотка, артка, китапка. 5. Бәйләгеч кушымчалары булган рәтне күрсәтегез: а) саргылт, берәү, китә; ә) бәйрәмнәр, аклар, яшьләр; б) китабы, күлләр, өстәлендә; в) кунак, тукмак, сагынып. 6. Тамыр+сүз ясагыч+форма ясагыч+бәйләгеч+бәйләгеч схемасына туры килерлек сүз: а) игенчеләребез; ә) китапчыгымны; б) дәгъвачыларыбыз; в) кибетчеләрен. 7. Бәйләгеч кушымчалар: а) исемдә сан, фигыльдә заман, зат-сан кушымчалары; ә) исемдә килеш, тартым, сүз ахырында килгән күплек сан кушымчалары һәм фигыльдә зат-сан кушымчалары; б) фигыльдә юнәлеш, исемдә килеш, сыйфатларда дәрәҗә кушымчалары; в) сан төркемчәләре кушымчалары, фигыльдә юклык һәм заман кушымчалары. 8. Тамырдаш сүзләр рәтен күрсәтегез: а) карлы, карлыган, карын; ә) көзге, көзән, көзен; б) җәймә, җәенке, җәен; в) башмак, башваткыч, башлы. 9. Морфологик нигез нәрсә ул? а) сүзнең төрләнә торган өлеше; ә) сүзнең форма ясагыч кушымчадан калган өлеше; б) сүзнең бәйләгеч кушымчадан калган өлеше; в) исемдә тартым, сан кушымчалары белән алынган сүз. 10. Грамматик кушымчалар алар: а) исемдә сан, килеш, тартым кушымчалары; ә) фигыльдә зат-сан кушымчалары; б) исемләшкән сыйфатларда килеш кушымчалары; в) затланышсыз фигыль формалары, юнәлеш, дәрәҗә, заман, юклык кушымчалары, сыйфатларда дәрәҗә кушымчалары, сан төркемчәләре кушымчалары, алмашлык төркемчәләре кушымчалары. 11.Унификс булган сүзне билгеләгез: а) тамга; ә) шәмдәл; б) ахмак; в) сырганак. 12. Кайсы сүздә нуль морфеманы күрсәтеп була? а) алмалар; ә) килгәннәр; б) барыгыз; в) көзге. 12. Тамырга билгеләмә а) сүзнең иң кечкенә берәмлеге; ә) сүзнең мәгънәгә ия иң кечкенә берәмлеге; б) сүзнең лексик мәгънәгә ия иң кечкенә берәмлеге; в) сүзнең лексик һәм грамматик мәгънәләргә ия иң кечкенә берәмлеге. 13. Полифункциональ кушымчалар кергән сүзләр төркемдә? а) тотка, китапка, ботка; ә) каенлык, утынлык, барырлык; б) бүлмә, төймә, үлмә; в) искечә, кисәкчә, үзенчә. 14. Кайсы төркемдәге сүзләрдә стилистик кушымча бар? а) уенчык, карчык; ә) татарча, яшьләрчә; б) төерчек, балакай; в) валчык, бушлай. 15. Кайсы тигезләмә дөрес? а) нигез= тамыр+сүз ясагыч+форма ясагыч; ә) нигез= тамыр+сүз ясагыч+форма ясагыч+бәйләгеч; б) нигез= тамыр + сүз ясагыч в) нигез= тамыр+сүз ясагыч. 2 нче вариант 1.Сүзформа составында мәгънәгә ия булган иң кечкенә кисәк: а) морф; ә) морфема; б) тамыр; в) кушымча. 2.Кайсы төркемдәге сүзләрнең барысы да морфемаларга дөрес бүленгән? а) ал-дыр-а, ки-ен-ә-м, кош-ны-ң; ә) иг-ен-ләтә, эш-лә-тә,өй-дән; б) бар-гала-ды, эт-тер-де, кеше-ләр-чә; в) кит-мә-гән, күтәр-ел-де, эш-лә-гәнне. 3. Кайсы төркемдәге сүзләр бер сүз ясалыш оясына керәләр? а) кабак, кабырга, кап; ә) бала, балак, бал; б) бүлмә, бүләк, бүленеш; в) кар, карак, карга. 4.Кайсы төркемдә синтетик сүзләр бирелгән? а) өчаяк, көньяк; ә) КДУ, АКШ; б) куркып китү, алып бирү; в) тракторчы, кунак. 5.Нинди сүзләр кушымчалау ысулы белән ясалмый? а) сан; ә) исем; б) рәвеш; в) фигыль. 6.Кайсы сүздә -ен кушымчасы фигыль ясый? а) төшенде; ә) эшенә; б) киенә; в) игенче. 7. Кайсы сүзнең морфологик нигезе дөрес билгеләнгән? а) сынатмадылар; ә) балаларымны; б) ашатыгыз; в) китапханәчеләр. 8. Сүз ясалышы ягыннан кайсы сүз артык? а) кием; ә) утынчы; б) җырласы; в) ташчы. 9. Полифункциональ кушымчалар кергән сүзләр төркемдә? а) тотка, китапка, ботка; ә) каенлык, утынлык, барырлык; б) бүлмә, төймә, үлмә; в) искечә, кисәкчә, үзенчә. 10. Ясалма сүзләр кайсы төркемдә? а) кабырга, карагач; ә) бавырга, карагач; б) тапкыр, кыйгач; в) аркасында, таба. 11. Кайсы төркемдә сүзтезмәләр тезмә сүз түгел? а) йорт куяны, хис итү; ә) җир җиләге, сабыр итү; б) сатылган мал, эчне бушату; в) үги ана яфрагы, тәэсир итү. 12. Кайсы сүз төркеме барлык төр ысуллар белән дә ясала? а) фигыль; ә) исем; б) сыйфат; в) барлык сүз төркемнәре дә. 13. Нинди сүзләр конверсия ысулы белән ясала алмый? а) рәвеш, ярдәмлек; ә) фигыль, сан; б) исем, сыйфат; в) ымлык, кисәкчә. 14. Кайсы төркемдә лексик-семантик ысул белән ясалган сүзләр бирелгән? а) ташчы, ял; ә) ай, ия; б) акыллы, сөйкемле; в) кара, бүлмә. 15. Кыскартылма сүзләрне төркемнәргә аерыгыз. (а) беренче хәрефләренең исемнәрен кушу, б) беренче авзларын кушу, в - беренче иҗекләрен кушу юлы белән; г) катнаш ысул белән ясалган кыскартылма сүзләр) 1. КДУ. 2. КамАЗ. 3. Продмаг. 4. АКШ. 5. Колхоз. 6. SMS. 7. НАТО. 8.ТИҮ.

4семестр

Тест.

1 нче вариант 1.Сүзләрне нәрсәгә таянып төркемлиләр? а) гомумиләштерелгән лексик-грамматик мәгънә; ә) грамматик категорияләр комплексы; б) сүзләрнең синтаксик вазифасы; в) алдагыларның өчесе дә. 2. Грамматик категория а) грамматик формалар системасы; ә) грамматик мәгънәләр җыелмасы, б) грамматик мәгънә һәм грамматик форма бердәмлеге, в) җаваплар дөрес түгел. 3.Су, каймак, ком, нәфрәт, ихтирам, тимер, агач, тәрәзә мисаллары арасында а) предметны белдерә торган ике исем; ә) җыелмалылыкны белдерә торган 3 исем; б) вакыйга-күренешне белдерә торган 2 исем; в) әйберне белдерә торган 4 исем бар. 4.Исем ясагыч кушымчалар кайсы төркемдә? а) -сыл, -сел, -малы,-мәле; ә) -ла,-лә,-ы,-е; б) -ганак,-гәнәк, -ымта, -емтә; в) -а,-ә, -ла,-лә. 5."Идел белән Җаектан, Сарай белән Болгардан, Программа дисциплины "Родной язык"; 44.03.05 Педагогическое образование (с

двумя профилями подготовки); профессор, д.н. (профессор) Галлямов Ф.Г. , старший преподаватель, к.н. Хайруллина А.С. Регистрационный номер 1016036619 Страница 34 из 55. Каргалы, Элек буеннан, Татарның тулы йортыннан Сина килдем, атаем" - өзегендәге исемнәр а) урын хәлләре; ә) аергычлар; б) тәмамлык һәм эндәш сүзләр; в) тәмамлыклар булып килгән. 6. Килеш функциясендә килгән сүз формасы кайсы төркемнәрдә? а) чираттагы утырыш, ә) бүтәнчә уйлау; б) йортыбыздагы маллар; г) эшчән кеше. 7.Җиргә эре бодай бөртекләре чәчелде (Г.Бәширов) җөмләсендәге сыйфат а) предметның формасын; ә) күләмен; б) характер билгесен; в) урынны белдерә. 8.Көлсу, моңсу, алсу, уйсу мисалларының кайсысын кимлек дәрәҗәсендәге сыйфат дип санап була? а) беренчесен; ә) икечесен; б) өченчесен; в) дүртенчесен. 9.Елмайганда тип-тигез тешләре күренеп китә. Аның тешләре тип-тигез җөмләләрендә курсив белән аерып бирелгән сүзләр а) бер үк җөмлә кисәкләре; ә) беренчесе - хәл, икечесе - хәбәр; б) беренчесе - аергыч, икенчесе - хәбәр; в) беренчесе - тәмамлык, икенчесе - хәбәр. 10.Идрисов фронтка бары тик 1942 елда гына эләгүен әйтеп бирде.Бу җөмләдә сан а) бүлем саны; ә) тәртип саны; б) җыю саны; в) микъдар саны. 11.Кил- һәм бул- фигыльләренең кайсы юнәлештә лексик мәгънәләре үзгәрә. а) йөкләтү; ә) уртаклык; б) кайтым; в) төшем. 12.Кайсы җөмләдә хәзерге заман хикәя фигыльнең парадигматик мәгънәсе бирелгән? а) Сания пөхтә киенә; ә) Кара әле, әллә нинди бер кош очып бара; б) Иртәгә апаларга барам; в) Ирек мактанырга ярата. 13.Кайтым юнәлешендәге фигыль кайсы төркемдә? а) Кичә укучылар концертка хәзерләнде; ә) Проект ике көндә хәзерләнде; б) Икенче срокка сайланды; в) Йорт бик тиз салынды. 14. Фигыль төркемчәсенең күрсәткече нуль форма булганы кайсысы? а) теләк фигыль; ә) инфинитив; б) исем фигыль; в) боерык фигыль. 15. Ярдәмче фигыль кайсысында? ә) дәвам итә; ә) гөж килү; б) кабул итү; в) укып бетерү. 16.Башта, соңыннан, иртәгә, бушка а) тамыр сүзләр; ә) конверсияләнеп ясалган рәвешләр; б) кушымчалау юлы белән ясалган рәвешләр; в) урын-ара килешендәге исемнәр. 17.Кинәт, вәхшиләрчә сүзләре икесе дә а) саф рәвешләр; ә) охшату-чагыштыру рәвешләре; б) күләм-чама рәвешләре; в) җаваплар дөрес түгел. 18. Берьюлы ике сүз төркеме билгеләренә ия булган сүз төркемнәре а) рәвеш, шарт фигыль, алмашлык; ә) сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль; б) инфинитив, боерык фигыль, хикәя фигыль; в) сан, исем, алмашлык. 19.-рак,-рәк кушымчасы ялгана ала торган сүз төркемнәре а) сыйфат; ә) сыйфат, рәвеш; б) сыйфат, рәвеш, хәл фигыль; в) саналганнарның барысына да һәм кайбер бәйлекләргә, хәбәрлек сүзләргә ялгана. 20. Тонык, ихтимал, бормалы, чимал, кирәк, җирле, күрәләтә мисаллары арасында а) ике төрле; ә) өч төрле; б) дүрт төрле; г) биш төрле сүз төркеме бар. 21.Сүзбәйләгечләр кайсы төркемдә? а) аркылы, карамастан, ник дисәң; ә) иң, әллә, мөгаен; б) билләһи, түгел, хәтта; в) шулай да, шуңа күрә. 22.Грамматик категорияләре иң күп булган сүз төркеме. а) исем; ә) фигыль; б) сыйфат; в) рәвеш. 23.Исемнәрдә күплек сан кушымчаларының ничә варианты бар? а) 2; ә) 3; б) 4; в) 6. 24. Татар телендә фигыльләрнең ничә үткән заман төре бар? а) 2; ә) 3; б) 4; в) 5. 25.Татар телендә фигыльләрнең ничә юнәлеше бар? а) 3; ә) 4; б) 5; в) 6. 26. Аның юлы ерак түгел иде (К.Нәҗми) җөмләсендә рәвеш: а) хәл булып килә; б) аергыч булып килә; б) хәбәр составында килә; в) җөмлә кисәге түгел. 27. Ясалышы ягыннан саннарның түбәндәге төрләре була: а) тамыр, кушма, тезмә; ә) гади, тамыр, кушма, парлы; б) гади, кушма, тезмә, өлеш; в) тамыр, кушма, парлы, чама. 28.Дөрес, билгеле, кызганыч, диярсең, бәхәссез, һичшиксез, ихтимал, икән сүзләре: а) барысы да модаль сүзләр ә) модаль сүз дә, мөстәкыйль сүз дә була алалар; б) беренче дүртесе модаль сүз дә, мөстәкыйль сүз дә була ала; в) беренче бишесе модаль сүз дә, мөстәкыйль сүз дә була ала. 29. Кайсы төркемгә бер теркәгеч ялгыш кергән? а) иярткуче теркәгечләр: гүя, ягъни, әгәр; ә) җыючы теркәгечләр: тагы, бигрәк тә, һәм; б) каршы куючы теркәгечләр: фәкать, ә, исә. в) бүлүче теркәгечләр: яки, яисә, әле-әле. 30. Сай коелы бакча, зур ишекле бүлмә, сай фикерле кеше, ачык чырайлы кеше мисалларында сүзтезмәнең, ясагыч кушымча алып, кушма сүзгә күчү ысулы белән а) бер сыйфат; ә) ике сыйфат; б) өч сыйфат; в) дүрт сыйфат ясалган.

5семестр

Тест.

1. Сүзнең мәгънәле кисәкләрен өйрәнә торган бүлек: а) сүз ясалышы; б) мофология; в) сүз төзелеше; г) синтаксис. 2. Яфраклар саргайды җөмләсендәге курсив белән аерып бирелгән сүздә морфемалар чигендә нинди күренеш күзәтелә; а) морфонологик күренеш; б) морфологик күренеш; в) синтаксис күренеш; г) монда бернинди күренеш тә күзәтелми. 3. Теләктәшлек сүзе ничә морфемадан (мәгънәле кисәктән) тора? а) өч; б) дүрт; в) биш; г) алты. 4. Грамматиканың сүзләр, җөмләләр бәйләнешен өйрәнә торган бүлеге а) морфемика; б) морфология; в) сүз ясалышы; г) синтаксис. 5. Грамматиканың яңа сүзләр барлыкка килү ысулларын, юлларын, чарала-рын өйрәнә торган бүлеге бүлеге а) морфемика; б) морфология; в) сүз ясалышы; г) синтаксис. 6. Сүзләрнең мәгънәле кисәкләргә бүленеше кайсы пунктта дөрес бирелгән а) бор-га-ла-т-тыр-ма-ды; б) бор-гала-т-тыр-ма-ды; в) бор-галат-тыр-ма-ды; г) бор-гала-ттыр-ма-ды; 7. Аягында көчкә басып тора. Бу җөмләдә курсив хәрефләр белән аерып бирелгән сүз а) кушымчалау ысулы белән; б) икенче бер сүз төркеме күчү ысулы белән; в) аваз үзгәрешенә нигезләнеп; г) мәгънә үзгәреп, омоним туу исәбенә барлыкка килгән. 8. Атыңа ия чыгар (Ф.Хөсни). Ия ? җөмләнең баш кисәге. Икенче җөмләдә курсив хәрефләр белән аерып бирелгән сүз а) кушымчалау ысулы белән; б) икенче бер сүз төркеме күчү ысулы белән; в) аваз үзгәрешенә нигезләнеп; г) мәгънә үзгәреп, омоним туу исәбенә барлыкка килгән. 9. Тугры дус. Туры юл. Курсив хәрефләр белән аерып бирелгән сүз а) кушымчалау ысулы белән; б) икенче бер сүз төркеме күчү ысулы белән; в) аваз үзгәрешенә нигезләнеп; г) мәгънә үзгәреп, омоним туу исәбенә барлыкка килгән. 10. Кайсы формулировка дөрес: Хикәя фигыль а) зат-сан белән төрләнә; б) юнәлеш белән төрләнә; в) барлык-юклык белән төрләнә; г) заман белән төрләнә. 11. Һәркөнне кичләрен аяк, кулларыңны юып ятарга кирәк. Бу җөмләдә курсив белән аерылган сүз а) берлек сан һәм килештәге исем; б) баш килештәге исем; в) тартым белән төрләнмәгән баш килештәге исем; г) грамматик мәгънәләре берлек сан, 2 зат берлектәге тартым формасына туры килгән исем. 12. Кайсы формулировка дөрес? Хикәя фигыль а) зат-сан белән төрләнә; б) юнәлеш белән төрләнә; в) барлык-юклык белән төрләнә; г) заман белән төрләнә. 13. Кайсы фигыль кайтым юнәлеше формасы белән килеп яңа сүз ясый? а) бизәнү; б) киенү; в) үтенү; г) юыну. 14. Кайсы асыл сыйфатны чагыштыру һәм артыклык дәрәҗәләренә куеп карап булмый? а) яшь; б) карт; в) үле; г) өлкән. 15. Пәрәмәч! Син дә мондамыни?! Син булып син эшли алмадың. Әйтем шул! Курсив хәрефләр белән

аерып бирелгән сүзләрне нәрсә берләшиерә? а) мөстәкыйль сүз булулары; б) икенчебер сүз төркеменә күчеп ясалулары; в) тамыр сүз булулары; г) боларны берни дә берләштерми. 16. Бу теманы кайта-кайта өйрәнергә туры килә. Атлап кайта-кайта арып беттек. Курсив хәрефләр белән аерып бирелгән сүзләр а) икесе дә - парлы рәвешләр; б) икесе дә - хәл фигыль; в) беренчесе ? кабатланып килгән хәл фигыльнең рәвешкә күчкән очрагы; г) ике форма да эшнең үтәлү дәрәҗәсен белдерә. 17. Син күреп белгән теге адәм авылдан киткән. Бу җөмләдәге курсив хәрефләр белән аерып бирелгән фигыльләрнең а) икесендә дә нуль морфема бар; б) беренчесендә юк, икенчесендә бар; в) беренчесендә бар, икенчесендә юк; г) нуль морфема икесендә дә юк. 18. Раслау җөмлә кайсысы? а) Ел саен авылга кайтмый калмый; б) Монда керергә ярамый; в) Ул бүген килмәде; г) Бүген килергә исәбендә дә юк. 19. Кошлар сайравын мин бик яратам. Кошлар сайрауга мин битараф кала алмыйм. Болар ? а) икесе дә синтетик иярченле кушма җөмләләр; б) икесе дә - җәенке җыйнак җөмлаләр; в) беренчесе ? гади, икенчесе синтетик иярченле җөмлә; г) беренчесе ? кушма, икенчесе гади җөмлә.. 20. Син килүгә мин шатмын. Син килүгә, бу мәсьәләне хәл итәрбез. Син килгәнгә, ул аптырап калды. Бу җөмләләрнең мәгънә төрләре буенча урнашу тәртибе түбәндәгечә: а) вакыт җөмлә, максат җөмлә, шарт җөмлә; б) тәмамлык җөмлә, вакыт җөмлә, сәбәп җөмлә; в) тәмамлык җөмлә, вакыт җөмлә, максат җөмлә; г) тәмамлык җөмлә, күләм җөмлә, сәбәп җөмлә.

6 семестр

1. Бер составлы фигыль җөмләнең баш кисәге ? белән белдерелә.

а) теләсә нинди сүз төркеме, б) фигыль, в) фигыльдән башка сүз төркемнәре, г) исемнәр, д) рәвешләр

2. Атау җөмләләрнең баш кисәге ? белән белдерелә. а) фигыль, б) фигыльдән башка сүз төркемнәре, в) теләсә нинди сүз төркемнәре, г) исемнәр, д) ымлыклар

3. Шарт хәле эш яки хәлнең ? белдерә. а) киресе булуын, б) шартын, в) максатын, г) рәвешен, д) сәбәбен.

4. Сүзтезмә ? а) төшенчәне, күренешне гомумиләштереп атый; б) төгәлләп бирә; в) гомумиләштерә дә, төгәлли дә; г) аныклап бирә, д) яңалык хәбәр итә.

5. Күләм хәле эш яки хәлнең ? белдерә. а) вакытын, б) шартын, в) күләм-дәрәҗәсен, г) рәвешен, д) максатын.

6. Җөмләгә ? а) модальлек кенә, б) хәбәрлек кенә, в) модальлек һәм хәбәрлек хас; г) хәбәрлек, д) модальлек һәм хәбәрлек хас түгел.

7. Сүзләрнең кире тәртибе булганда, ? урнаша. а) ия хәбәрдән алда, б) аергыч аерылмыштан алда, в) тәмамлык, хәлләр иярчүчеләреннән алда, г) аныклагыч аныкланмышыннан соң, д) ия хәбәрдән, аергыч аерылмыштан, тәмамлык, хәлләр иярчүчеләреннән соң

8. Эмоциональ бизәге ягыннан җөмләләр ? булалар. а) тойгылы хикәя, б) тойгылы сорау, в) тойгылы боерык, г) саф тойгылы гына, д) тойгылы хикәя, тойгылы сорау, тойгылы боерык, саф тойгылы

9. Аергыч ? иярә. а) теләсә нинди сүз төркеменә, б) исемгә генә, в) сыйфатка гына, г) рәвешкә генә, д) фигыльгә генә

10. Җөмләнең модаль кисәкләренә? керә. а) эндәш сүзләр, б) кереш сүзләр,. в) ымлыклар, г) әйе, юк сүзләре, д) эндәш сүзләр, кереш сүзләр

11. Җыйнак җөмлә ? тора. а) бер генә сүздән, б) баш кисәкләрдән генә, в) баш һәм иярчен кисәкләрдән, г) иярчен кисәкләрдән, д) модаль кисәкләрдән генә

12. Кире хәл эш яки хәлнең ? белдереп килә. а) киресе булуын, б) шартын, в) сәбәбен, г) максатын, д) вакытын

13. Ия ? бирелә. а) баш килештә исем урынында килгән теләсә нинди сүз төркеме белән, б) билгесез килештәге сүзләр белән, в) баш килештәге сүз һәм бәйлек белән, г) иялек килешендәге исемнәр белән, д) төшем килешендәге сүзләр белән

14. Ияләр ? булалар. а) гади генә, б) тезмә генә, в) гади һәм тезмә, г) кушма, д) гади, тезмә, кушма

15. Модальлек ? белдерелә. а) хикәя, б) сорау, в) боерык, г) тойгылы җөмләләрне барлыкка китерүче чаралар белән, д) боларның барысы белән дә

16. Хикәя җөмләнең хәбәре ? белән белдерелә. а) боерык фигыль, б) теләк фигыль, в) шарт фигыль, г) хәл фигыль, д) хикәя фигыль

17. Эндәш сүзләр булып, ? килә. а) кеше исемнәре генә, б) туганлык терминнары гына, в) гомумән кешегә карата әйтелә торган сүзләр генә, г) җансыз предмет атамалары гына, д) боларның барысы да

18. Җәенке җөмлә ? оеша. а) баш кисәкләрдән генә, б) баш һам иярчен кисәкләрдән, в) баш һәм модаль кисәкләрдән, г) иярчен һәм модаль кисәкләрдән, д) иярчен кисәкләрдән генә

19. Гади җөмләдә ? а) хәбәрлек булмый, б) бер генә хәбәрлек, в) ике хәбәрлек, г) өч хәбәрлек, д) дүрт хәбәрлек була.

20. Ия ? а) бер кисәккә дә грамматик буйсынмый, б) хәбәргә, в) тәмамлыкка, г) хәлләргә, д) аныклагычка буйсына.

21. Кушма җөмлә ? ? җөмлә ул. а) аерымланган аныклагычлар белән катлауландырылган, б) ике хәбәрлек үзәге булган, в) тиңдәш кисәкләр белән катлауландырылган, г) аерымланган хәлләр белән катлауландырылган, д) аерымланган аергычлар һәм тәмамлыклар белән катлауландырылган

22. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр ? бәйләнәләр. а) җыючы, б) каршы куючы, в) бүлүче, г) иярүче теркәгечләр, д) каршылык, санау интонациясе белән

23. Синтетик аергыч җөмлә баш җөмләгә ? иярә. а) мөнәсәбәтле сүзләр, б) көттерү паузасы, в) кушымчалар, янәшәлек, г) иярүче теркәгечләр, д) тезүче теркәгечләр аша

24. Иярчен җөмләләрне ? карап төркемлиләр. а) мәгънәсенә һәм төзелешенә, б) теркәгечле һам теркәгечсез булуына, в) тезүле һәм иярүле булуына, г) җөмләдәге вазифасына, д) бәйләүче чарасына

25. Аналитик иярчен тәмамлык җөмләләр баш җөмләгә ? ярдәмендә бәйләнә. а) дип сүзе һәм төшем килеш кушымчасы, б) төшем килеш кушымчасы һәм янәшәлек, в) юнәлеш килеш кушымчасы һәм дип сүзе, г) ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр, көттерү паузасы, ки теркәгече, д) килеш кушымчалары, ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр

26. Синтетик аергыч җөмлә баш җөмләгә ? ярдәмендә бәйләнә. а) ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр; б) янәшәлек, иялек килеш кушымчасы, сыйфат фигыль кушымчалары; в) янәшәлек көттерү паузасы, ки теркәгече; г) ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр, көттерү паузасы, ки теркәгече; д) сыйфат фигыль кушымчалары, көттерү паузасы, ки теркәгече

27. Аналитик иярчен вакыт җөмләләр баш җөмләгә ? ярдәмендә бәйләнә. а) төрле фигыль формалары, ул да түгел теркәгеч сүзе; б) килеш кушымчаларын кабул иткән төрле фигыль формалары; в) төрле бәйлек һәм бәйлек сүзләр; г) ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр, ул да түгел теркәгеч сүзе; д) ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр, төрле бәйлек һәм бәйлек сүзләр 28. Синтетик иярчен урын җөмлә баш җөмләгә ? ярдәмендә бәйләнә. а) парлы һәм ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр; б) якта, яктан бәйлек сүзләре, ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр; в) якта, яктан җирдә, җирдән, урында, төштә, төштән бәйлек сүзләре; г) җирдә, җирдән бәйлек сүзләре, ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр; д) төштә, төштән бәйлек сүзләре, парлы һәм ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр

29. Аналитик иярчен рәвеш җөмләләр баш җөмләгә ? ярдәмендә бәйләнә. а) парлы һәм ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр, хәл фигыль кушымчалары; б) гүя теркәгече, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, рәвеш ясаучы кушымчалар, хәл фигыль кушымчалары; в) парлы һәм ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр, гүя теркәгече, -мыни, -мени сорау кушымчалары (кисәкчәләре), рәвеш ясаучы кушымчалар; г) парлы һәм ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр, гүя теркәгече, -мыни, -мени сорау кушымчалары (кисәкчәләре); д) бәйлек һәм бәйлек сүзләр, рәвеш ясаучы кушымчалар, хәл фигыль кушымчалары

30. Синтетик иярчен күләм җөмлә баш җөмләгә ? ярдәмендә бәйләнә. а) кадәр, хәтле бәйлекләре, дәрәҗәдә бәйлек сүзе, мөнәсәбәтле сүзләр һәм ки теркәгече;. б) кадәр, хәтле бәйлекләре, дәрәҗәдә бәйлек сүзе ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр; в) кадәр, хәтле бәйлекләре, дәрәҗәдә бәйлек сүзе белән; г) кадәр, хәтле бәйлекләре, дәрәҗәдә бәйлек сүзе белән парлы һәм ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр; д) кадәр, хәтле бәйлекләре, дәрәҗәдә бәйлек сүзе белән ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр, мөнәсәбәтле сүзләр һәм ки теркәгече

4.2. Оценочные средства промежуточной аттестации

4.2.1. Экзамен

4.2.1.1. Порядок проведения.

Промежуточная аттестация нацелена на комплексную проверку освоения дисциплины. Обучающийся получает вопрос(ы)/задание(я) и время на подготовку. Промежуточная аттестация проводится в устной, письменной или компьютерной форме. Оценивается владение материалом, его системное освоение, способность применять нужные знания, навыки и умения при анализе проблемных ситуаций и решении практических заданий.

4.2.1.2. Критерии оценивания.

Экзамен

Оценка «отлично» ставится, если обучающийся продемонстрировал всестороннее, систематическое и Промежуточная аттестация нацелена на комплексную проверку освоения дисциплины. Обучающийся получает вопрос(ы)/задание(я) и время на подготовку. Промежуточная аттестация проводится в устной, письменной или компьютерной форме. Оценивается владение материалом, его системное освоение, способность применять нужные знания, навыки и умения при анализе проблемных ситуаций и решении практических заданий.

4.2.1.1. Порядок проведения.

Каждая часть экзамена оценивается максимально в 25 баллов, а затем баллы суммируются, в итоге студент может заработать 50 баллов

4.2.1.2. Критерии оценивания.

Баллы в интервале 43-50 от максимальных ставятся, если обучающийся продемонстрировал всестороннее, систематическое и глубокое знание учебно-программного материала, умение свободно выполнять задания, предусмотренные программой, усвоил основную литературу и знаком с дополнительной литературой, рекомендованной программой дисциплины, усвоил взаимосвязь основных понятий дисциплины в их значении для приобретаемой профессии, проявил творческие способности в понимании, изложении и использовании учебно-программного материала.

Баллы в интервале 35-42 от максимальных ставятся, если обучающийся продемонстрировал полное знание учебно-программного материала, успешно выполнил предусмотренные программой задания, усвоил основную литературу, рекомендованную программой дисциплины, показал систематический характер знаний по дисциплине и способен к их самостоятельному пополнению и обновлению в ходе дальнейшей учебной работы и профессиональной деятельности.

Баллы в интервале 28-34 от максимальных ставятся, если обучающийся продемонстрировал знание основного учебно-программного материала в объеме, необходимом для дальнейшей учебы и предстоящей работы по профессии, справился с выполнением заданий, предусмотренных программой, знаком с основной литературой, рекомендованной программой дисциплины, допустил погрешности в ответе на экзамене и при выполнении экзаменационных заданий, но обладает необходимыми знаниями для их устранения под руководством преподавателя.

Баллы в интервале 0-27 от максимальных ставятся, если обучающийся продемонстрировал знание основного учебно-программного материала в объеме, необходимом для дальнейшей учебы и предстоящей работы

по профессии, справился с выполнением заданий, предусмотренных программой, знаком с основной литературой, рекомендованной программой дисциплины, допустил погрешности в ответе на экзамене и при выполнении экзаменационных заданий, но обладает необходимыми знаниями для их устранения под руководством преподавателя.

4.2.1.3. Содержание оценочного средства

4 семестр

Часть1.Устный или письменный ответ на теоретический вопрос по курсу дисциплины:

1. Фонетика фәне. Аның тел гыйлеменең башка тармаклары белән бәйләнеше.
2. Фонетиканың төп бүлекләре.
3. Фонетика фәненең тикшеренү ысуллары.
4. Татар теле фонетик системасының өйренелү тарихы.
5. Сөйләм авазын билгеләүнең өч аспекты.
6. Сөйләм аппаратының төзелеше.
7. Аваз һәм фонема.
8. Сузыкларны телнең горизонталь хәрәкәте буенча төркемләү.
9. Сузыкларны телнең вертикаль хәрәкәте буенча төркемләү.
10. Тартыкларны ясалу урынына карап классификацияләү.
11. Сөйләмнең фонетик кисәкләргә бүленеше
12.Аваз үзгәрешләре.
13. Комбинатор аваз үзгәрешләре.
14. Тартыклар ассимиляциясе.
15. Сузыклар ассимиляциясе.
16. Аккомодация.
17. Диссимиляция.
18. Позицион аваз үзгәрешләре.
19.Редукция.
20. Иҗек. Иҗек калыплары.
21. Басым. Аның төрләре.
22. Җөмлә просодикасы буларак интонация.
23. Авазларның артикуляцион билгеләре.
24. Авазларның акустик билгеләре.
25. Дифтонглар.
26. Шаулы һәм сонант тартыклар.
27. Орфография. Аның принциплары.
28. Орфоэпия. Лексикология фәне һәм аның тармаклары.
29.Семасиология фәне. Аның өйрәнелү объекты.
30.Сүзнең күчерелмә мәгънәләре.Метафора, синекдоха, метонимия, функция буенча күчеш, табу һәм эвфемизмнар.
31.Омонимнар һәм аларның төрләре. Омонимнарның сөйләмдәге һәм матур әдәбияттагы роле. 5. Лексик омонимнар. Грамматик омонимнар. Әйтелеш һәм язылыш буенча омонимнарның төрләре.
32.Синонимнар һәм аларның төрләре. Синонимнарның сөйләмдәге һәм матур әдәбияттагы роле. Идеографик синонимнар. Стилистик синонимнар.Грамматик синонимнар. Контекстуаль синонимнар.
Антонимнар һәм аларның төрләре. Аларның сөйләмдәге һәм матур әдәбияттагы роле.
33.Килеп чыгышы ягыннан татар теленең лексикасы. Татар телендә алынмалар. Гарәп-фарсы алынмалары. Рус теленнән һәм рус теле аша кергән алынмалар. Фин-угор алынмалары.
34. Кулланылыш сферасы ягыннан татар теленең лексикасы. Диалектизмнар. Терминнар. Жаргон һәм арго сүзләр.
35.Кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан татар теленең лексикасы. Тарихи сүзләр. Архаизмнар. Неологизмнар.
36.Татар теленең ономастикасы. Топонимика, антропонимика.
37.Татар фразеологиясе. Фразеологизмнарның төрләре. . Идиомалар. 3Фразеологик ныгымалар. Фразеологик тезмәләр. Фразеологик терминнар.
38.Татар лексикографиясе. Сүзлекләрнең төрләре. Телнең сүзлек составын өйрәнү аспектлары. Этимология һәм аның төп принциплары.

Часть 2. Практическое задание (проверка практических навыков)

5семестр

Часть1.Устный или письменный ответ на теоретический вопрос по курсу дисциплины:

1. Сүзьясалышы фәне. Анын өйрәнү предметы һәм бурычлары. 2. Морфема. Аның төрләре. Сүзнең морфологик нигезе һәм ясагыч нигезе. 3. Морфонология. Морфонологик үзгәрешләр. Сүз һәм сүз формалары. 4. Тамыр һәм кушымча. Аларның охшаш һәм аермалы яклары. 5. Татар телендә унификс һәм интерфикслар. 6. Кушымча. Аның мәгънәсе, функция буенча төрләре. 7. Кушма сүзләр арасында бәйләнеш төрләре. 8. Кушма сүзләрнең ирекле сүзтезмәләрдән аермалы яклары. 9. Компонентлары тезүле бәйләнештә булган кушма сүзләр ясалышы. 10. Татар телендә сүз ясагыч кушымчалар. Аларның төрләре. 11. Грамматик кушымчалар. Аларның төрләре. 12. Татар телендә нуль морфема. Аның белдерелүе. 13. Татар телендә ясалма сүзләр. Аларның төрләре. 14. Татар телендә ясалма булмаган сүзләр. 15. Кыскартылма сүзләр. Аларның ясалу ысуллары. 16. Сүзьясалыш чылбыры һәм сүзьясалыш

оясы. 17. Татар телендә сүз ясалу ысуллары. Грамматик һәм грамматик булмаган ысуллар. 18. Нигезләр кушылу ысулы. 19. Фонетик ысул. 20. Лексик-семантик ысул. 21. Конверсия ысулы. 22. Кушымчалау ысулы. 23. Сүзтезмәнең кушма сүзгә күчү ысулы. 24. Сүзтезмәнең, кушымча алып, кушма сүзгә күчү ысулы. 25. Аналитик сүзләр. 26. Синтетик сүзләр. 27. Кушымчалау нигезендә исемнәр, фигыльләр ясалышы. 28. Исемнәрнең фонетик ысул белән ясалышы. 29. Кушма исемнәр ясалышы. 30. Конверсия ысулы белән исемнәр ясалышы. 31. Лексик-семантик ысул белән исемнәр ясалышы. 32. Фонетик ысул белән фигыльләр ясалышы. 33. Сыйфатлар һәм рәвешләр ясалышы.
1. Исемдә тартым һәм сан категорияләре. 2. Исемдә килеш категориясе. 3. Исемдә хәбәрлек категориясе. 4. Исемнәрнең ясалышы. Аларның җөмләдәге синтаксик вазифалары. 5. Сыйфат. Аның төркемчәләре. Сыйфат дәрәҗәләре. 6. Сыйфатларның исемләшүе. 7. Сыйфатларның ясалу юллары. 8. Рәвеш. Рәвешләрнең мәгънә буенча төркемчәләре. 9. Саннар. Аларның төркемчәләре. Саннарның ясалышы. 10. Алмашлыклар. Аларның төркемчәләре. 11. Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләр. 12. Фигыльдә заман категориясе. 13. Фигыльнең барлык-юклык формасы. Зат категориясе. 14. Хикәя фигыльнең заман формалары. 15. Фигыльдә юнәлеш категориясе. 16. Фигыльдә дәрәҗә категориясе. 17. Фигыль наклонениеләре. 18. Затланышсыз фигыль формалары. 19. Сыйфат фигыль. 20. Хәл фигыль. Аның төрләре. 21. Инфинитив һәм исем фигыль. 22. Фигыльнең башлангыч формасы. Кушымчалар нигезендә фигыльләр ясалышы. 23. Мөстәкыйль мәгънәле һәм ярдәмче фигыльләр. 24. Фигыльләрнең ясалышы.

6 семестр

Часть1.Устный или письменный ответ на теоретический вопрос по курсу дисциплины:

1. Синтаксис һәм аның төп өйрәнү объекты. Җөмләнең төп үзенчәлекләре. 2. Интонация һәм аның сөйләмдәге роле, аның компонентлары. 3. Сүзләр арасында иярткуле бәйләнеш һәм аны белдерүче чаралар. 4. Сүзләр арасында тезүле бәйләнеш һәм аны белдерүче чаралар. 5. Сүзтезмә һәм аның төрләре. 6. Фигыль сүзтезмәләр һәм аларның төп үзенчәлекләре. 7. Исем сүзтезмәләр һәм аларның төп үзенчәлекләре. 8. Сыйфат сүзтезмәләр һәм аларның төп үзенчәлекләре. 9. Җөмләнең кисәкләргә традицион бүленеше һәм аның сүзләр бәйләнешен өйрәнүдә тоткан әһәмияте. 10. Ия һәм аның төп билгеләре. 11. Хәбәр һәм аның белдерелүе. Исем хәбәрнең үзенчәлекләре. 12. Фигыль хәбәрләр һәм аның үзенчәлекләре. 13. Ия һәм хәбәрнең үзара бәйләнеше һәм аны белдерүче чаралар. 14. Аергыч һәм аның җөмләдәге урыны, аларның бирелеше һәм иярткуче кисәккә бәйләнү юллары. 15. Тәмамлык һәм аның үзенчәлекләре, төрләре. 16. Вакыт һәм урын хәлләре, аларның бирелеше һәм иярткуче кисәккә бәйләнү юллары. 17. Рәвеш һәм күләм хәлләре. 18. Сәбәп һәм максат хәлләре. 19. Шарт һәм кире хәл үзенчәлекләре. 20. Аныклагычлар һәм аларның төп үзенчәлекләре. 21. Җөмләнең модаль кисәкләре. 22. Җөмләнең тиңдәш кисәкләре. 23. Аерымланган иярчен кисәкләр. 24. Җөмләнең аерымланган кисәкләре янында тыныш билгеләре. 25. Актуаль кисәкләр һәм аларның белдерелү юллары. 26. Җөмләдә сүз тәртибенең роле һәм төрле стильләрдә аны белдерүче факторлар. 27. Гади сөйләмдә сүз тәртибен билгеләүче факторлар. Җөмлә кисәкләренең урыны. 28. Бер составлы фигыль җөмләләр. 29. Атау һәм сүз җөмлә үзенчәлекләре. 30. Тулы һәм ким җөмлә үзенчәлекләре, 31. Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре. 32. Өстәлмәләр. 33. Кушма җөмләләр турында гомуми мәгълүмат. Кушма җөмләләрне төркемләү мәсьәләсе. 34. Җөмләнең синтагмаларга бүленеше.
35.Кушма җөмләләр турында гомуми мәгълүмат.Кушма җөмләләрне төркемләү мәсьәләсе. Кушма җөмләләрне компонентлар саныннан чыгып төркемләү. Кушма җөмләләрне бәйләнеш төреннән, төзелешеннән чыгып төркемләү. Кушма җөмләләрне мәгънәләреннән (функцияләреннән чыгып) төркемләү.
36.Тезмә кушма җөмлә үзенчәлекләре.Тезмә кушма җөмләләрне төзелешеннән чыгып төркемләү. Тезмә кушма җөмләләрне оештыруда интонациянең роле. Тезмә кушма җөмләләрне оештыруда катнаша торган теркәгечләр. Тезмә кушма җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре. Тезмә кушма җөмләләрнең төп бәйләүче чаралары.
37.Иярченле кушма җөмлә. Ия һәм хәбәр җөмлә үзенчәлекләре, аның баш җөмләгә бәйләнү юллары.Иярчен ия җөмләләрнең аналитик һәм синтетик төрләре. Ия җөмләләрнең ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр белән бәйләнеше.Бәйләүче чарасы парлы мөнәсәбәтле сүзләр булган ия җөмләләр. Көттерү паузасы белән бәйләнгән ия җөмләләр.
38.Аналитик хәбәр җөмләләрнең бәйләүче чарарлары булып, мөнәсәбәтле сүзләр, көттерү паузасы.
39.Тәмамлык җөмлә үзенчәлекләре, аның баш җөмләгә бәйләнү юллары.
40.Аергыч җөмлә үзенчәлекләре, аның баш җөмләгә бәйләнү юллары.
41.Аналитик һәм синтетик төзелешле тәмамлык һәм аергыч җөмләләр.
42.Аналитик тәмамлык һәм аергыч җөмләләрнең ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр белән бәйләнеше.
43.Көттерү паузасы белән бәйләнгән тәмамлык һәм аергыч җөмләләр.
44.Килеш кушымчылары белән бәйләнгән тәмамлык һәм аергыч җөмләләр.
45.Иярчен хәл җөмлә.
46.Катнаш кушма җөмлә.
47.Текст.

Часть 2. Практическое задание (проверка практических навыков)

Приложение 2
к рабочей программе дисциплины (модуля)
Б1.О.08.01.08 Родной язык

Перечень литературы, необходимой для освоения дисциплины (модуля)

Направление подготовки: 44.03.05 Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)
Профиль подготовки: Русский язык, родной (татарский) язык и литература
Квалификация выпускника: бакалавр
Форма обучения: очное
Язык обучения: русский
Год начала обучения по образовательной программе: 2025

Основная литература:

1. Хуснетдинов, Р. М. Татарский язык : практикум / Р. М. Хуснетдинов. - Казань : КНИТУ, 2019. - 88 с. - ISBN 978-5-7882-2693-4. - Текст : электронный // ЭБС "Консультант студента" : [сайт]. - URL : https://www.studentlibrary.ru/book/ISBN9785788226934.html (дата обращения: 07.02.2025). - Режим доступа : по подписке.

2. Латфуллина, Л. Г. Татарский язык. Начальный курс / Л. Г. Латфуллина - Санкт-петербург : КАРО, 2019. - 288 с. - ISBN 978-5-9925-1347-9. - Текст : электронный // ЭБС "Консультант студента" : [сайт]. - URL : https://www.studentlibrary.ru/book/ISBN9785992513479.html (дата обращения: 07.02.2025). - Режим доступа : по подписке.

3. Вьюгина, С. В. Деловой татарский язык : учебное пособие / С. В. Вьюгина - Казань : Издательство КНИТУ, 2017. - 204 с. - ISBN 978-5-7882-2259-2. - Текст : электронный // ЭБС "Консультант студента" : [сайт]. - URL : https://www.studentlibrary.ru/book/ISBN9785788222592.html (дата обращения: 07.02.2025). - Режим доступа : по подписке.

4. Хуснетдинов, Р. М. Практический татарский язык : учебное пособие / Хуснетдинов Р. М. - Казань : Издательство КНИТУ, 2017. - 388 с. - ISBN 978-5-7882-2236-3. - Текст : электронный // ЭБС "Консультант студента" : [сайт]. - URL : https://www.studentlibrary.ru/book/ISBN9785788222363.html(дата обращения: 07.02.2025). - Режим доступа : по подписке.

Дополнительная литература:

1. Хуснетдинов, Р. М. , Занимательный татарский язык : учебно-методическое пособие / Р. М. Хуснетдинов, С. В. Вьюгина. - Казань : КНИТУ, 2020. - 252 с. - ISBN 978-5-7882-2857-0. - Текст : электронный // ЭБС "Консультант студента" : [сайт]. - URL : https://www.studentlibrary.ru/book/ISBN9785788228570.html (дата обращения: 07.02.2025). - Режим доступа : по подписке.

2. Хуснетдинов, Р. М. Татарский язык: практикум : учебное пособие / Р. М. Хуснетдинов. — Казань : КНИТУ, 2019. — 88 с. — ISBN 978-5-7882-2693-4. — Текст : электронный // Лань : электронно-библиотечная система. — URL: https://e.lanbook.com/book/196106(дата обращения: 07.02.2025). — Режим доступа: для авториз. пользователей.

3. Актуальные проблемы изучения и преподавания татарской филологии : сборник научных трудов. — Уфа : БГПУ имени М. Акмуллы, 2016. — 390 с. — ISBN 978-5-87978-956-0. — Текст : электронный // Лань : электронно-библиотечная система. — URL: https://e.lanbook.com/book/93043 (дата обращения: 07.02.2025). — Режим доступа: для авториз. пользователей.

4. Практикум по татарскому языку : учебно-методическое пособие / составитель И. С. Насипов. — Уфа : БГПУ имени М. Акмуллы, 2017. — 90 с. — Текст : электронный // Лань : электронно-библиотечная система. — URL: https://e.lanbook.com/book/96833 (дата обращения: 07.02.2025). — Режим доступа: для авториз. пользователей.

Приложение 3
к рабочей программе дисциплины (модуля)
Б1.О.08.01.08 Родной язык

Перечень информационных технологий, используемых для освоения дисциплины (модуля), включая перечень программного обеспечения и информационных справочных систем

Направление подготовки: 44.03.05 Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)
Профиль подготовки: Русский язык, родной (татарский) язык и литература
Квалификация выпускника: бакалавр
Форма обучения: очное
Язык обучения: русский
Год начала обучения по образовательной программе: 2025

Освоение дисциплины (модуля) предполагает использование следующего программного обеспечения и информационно-справочных систем:

Программное обеспечения Office Professional plus 2010, Kaspersky Endpoint Security для Windows

Учебно-методическая литература для данной дисциплины имеется в наличии в электронно-библиотечной системе "ZNANIUM.COM", доступ к которой предоставлен обучающимся. ЭБС "ZNANIUM.COM" содержит произведения крупнейших российских учёных, руководителей государственных органов, преподавателей ведущих вузов страны, высококвалифицированных специалистов в различных сферах бизнеса. Фонд библиотеки сформирован с учетом всех изменений образовательных стандартов и включает учебники, учебные пособия, учебно-методические комплексы, монографии, авторефераты, диссертации, энциклопедии, словари и справочники, законодательно-нормативные документы, специальные периодические издания и издания, выпускаемые издательствами вузов. В настоящее время ЭБС ZNANIUM.COM соответствует всем требованиям федеральных государственных образовательных стандартов высшего образования (ФГОС ВО) нового поколения.

Учебно-методическая литература для данной дисциплины имеется в наличии в электронно-библиотечной системе Издательства "Лань" , доступ к которой предоставлен обучающимся. ЭБС Издательства "Лань" включает в себя электронные версии книг издательства "Лань" и других ведущих издательств учебной литературы, а также электронные версии периодических изданий по естественным, техническим и гуманитарным наукам. ЭБС Издательства "Лань" обеспечивает доступ к научной, учебной литературе и научным периодическим изданиям по максимальному количеству профильных направлений с соблюдением всех авторских и смежных прав.

Учебно-методическая литература для данной дисциплины имеется в наличии в электронно-библиотечной системе "Консультант студента", доступ к которой предоставлен обучающимся. Многопрофильный образовательный ресурс "Консультант студента" является электронной библиотечной системой (ЭБС), предоставляющей доступ через сеть Интернет к учебной литературе и дополнительным материалам, приобретенным на основании прямых договоров с правообладателями. Полностью соответствует требованиям федеральных государственных образовательных стандартов высшего образования к комплектованию библиотек, в том числе электронных, в части формирования фондов основной и дополнительной литературы.